ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 13 марты**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 486**

Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының «2029 нчы елга кадәр Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасы» проектын раслау турында» 2015 елның 27 мартындагы 04-03-31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә таләпләр турында»2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының «2029 елга кадәр Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасы» проектын раслау турында» 2015 елның 27 мартындагы 04-03-31 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Җылылык энергиясе һәм җылылык йөкләнеше чыганакларының җылылык куәте перспективалы балanslары» 3 бүлектәге 3.1 пунктны, кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2. «Төзелешкә, реконструкциягә һәм техник яктан яңадан җиһазландыруга инвестицияләрне нигезләү» бүлегендәге 9.1 пунктын яңа редакциядә, кушымтада каралганча, бәян итәргә;

1.3. «Җылылык энергиясе чыганаклары гамәлдә булган зоналарындагы җылылык энергиясе кулланучыларның, җылылык энергиясе кулланучылар төркемнәренең җылылык йөкләнешләре» 1.5.4 пунктының 5 нче өлешендәге «Җылылык энергиясе чыганаклары гамәлдә булган зоналарында тышкы һаваның исәпләнгән температурасында җылылык энергиясен куллану

күрсәткечләре»11 нче таблицаны, кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.О.Котельниковка:

2.1. Әлеге карар кабул ителгән көннән алып, 15 көн эчендә , аны Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында , Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының «2029 нчы елга кадәр Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасы» проектын раслау турында» 2015 елның 27 мартындагы 04-03-31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында 2017 елның 13 мартындагы 486 номерлы карарына кушымта

1. 3.1 пункт 3 нче бүлек :

А микрорайоны котельныенда табигый газны атмосфера һавасы белән аралаштыру өчен блоклы автоматлаштырылган система урнаштыру.

2. 9.1 пункт, 9 нчы бүлек:

- мазутта эшләүче резерв ягулык хуҗалыгын мич ягулыгында эшли торган авария ягулык хуҗалыгына күчереп, «А» микрорайоны котельныен проектлау һәм техник яктан яңадан җиһазлау;

- А микрорайоны котельныенда табигый газны атмосфера һавасы белән аралаштыру өчен блоклы автоматлаштырылган система урнаштыру.

- АСУТП ЦТП системасын реконструкцияләү (А микрорайоны котельные ЦТП 1,2,3,4,5,6,7, КРТП 1,2,3,4,5,6,7 , ЦТП 1.кв.1-7);

- Зеленодольск шәһәрендә Засорин урамындагы котельныйның 29-31 кв. автоматлаштырылган казан белән техник яктан яңадан җиһазлау;

- К.Маркс урамындагы 8а ТКсыннан алып КК-9га кадәр (2ф530 - 168м) Паратск урамындагы котельныйның 1-7 кв. ТС реконструкцияләү;

- Жуков урамындагы ТК-1 дән алып ТК-17 гә кадәр (2 этап) (2ф 630 - 90м) А микрорайоны котельные тс реконструкцияләү;

- Жуков -Төзүчеләр урамы буенча ТК-18/3 дән ТК-20 гә кадәр (3 этап) (2ф 530 -300м, 2ф425-234 м) А микрорайоны котельныен реконструкцияләү;

- Зеленодольск шәһәре Тургенев урамы буенча ТК-22 дән алып ТК-26 га кадәр (2ф250-354м) . котельныйның 1-7 кв. җылылык белән тәэмин итү челтәрләрен проектлау һәм реконструкцияләү ;

- Зеленодольск шәһәре Декабристлар урамы буенча ТК-5 тән алып ТК-5/16 кадәр (2ф250 - 376м, 2ф300-271м) котельныйның 1-7 кв. җылылык белән тәэмин итү челтәрләрен проектлау һәм реконструкцияләү;

- К.Маркс 57а урамындагы торак йортка (2ф125-125м, ф80/50-125м) котельныйның 22А кв.җылылык челтәрләрен реконструкцияләү. ;

- Паратск урамы буенча котельныйның 1-7 кв. К.Маркс (2ф500-600м) урамы буенча ТК-7гә кадәр җылылык челтәрләрен реконструкцияләү.

Чараларны гамәлгә ашыру еллар буенча финанс ихтыяҗларының гомуми күләме 520 млн. сум тәшкил итә (НДСтан башка).

3. 1.5.4 пункт, 5 нче өлеш, 11 нче таблица:

| Котельныйның исеме | Җылылык энергиясен эшкәртү |
|---|---|

| | бер ел эчендә, Гкал |
|---|---|
| «А» микрорайоны котельные | 198388 |
| Ерак ур.котельные | 3576 |
| 1-7 кв. котельные | 118788 |
| 22А кв. котельные | 39283 |
| 12 кв. котельные | 48679 |
| 19 кв.котельные | 48123 |
| 29-31кв. котельные | 26927 |
| 8кв. котельные | 2586 |
| 86 кв.котельные | 18734 |
| Мәктәп-интернат котельные | 609 |
| Загородная котельные | 2726 |
| **БАРЛЫГЫ** | **478419** |

Зеленодольск шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасын үстерүнең 1 этабында, торак фонды һәм шәһәр инфраструктурасы объектлары буенча тоташтырылган җылылык йөкләнешләрен арттыруны исәпкә алып, шулай ук кулланучыларда җылылык энергиясен исәпкә алу приборларын урнаштыру белән бәйле рәвештә, җылылык энергиясен файдалы җибәрү түбәндәге дәрәҗәдә көтелә:

- 2016 ел - 432 868,0 Гкал;
- 2017 ел - 439 790,0 Гкал;

2018 ел - 439 790,0 Гкал.